КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 сентябрь г.Казань № 856

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 924 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне

оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 924 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Күзәтчелек һәм тикшерүдә тоту рискка юнәлдерелгән алымны кулланып гамәлгә ашырыла.

Күзәтчелекне һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда рискка юнәлдерелгән алымны куллану максатларында эш бирүчеләрнең эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тикшерүенең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда рискка юнәлдерелгән алымны куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары белән расланган Юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар куллана торган җитештерү объектларын билгеле бер риск категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре нигезендә рискның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле $16^1$ – $16^6$ нчы пунктлар өстәргә:

«$16^1$. Эш бирүчеләр эшчәнлеген рискның билгеле бер категорияләренә кертү, эш бирүченең инвалидларны эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрнең мөмкин булган үтәлмәве аркасында салынган потенциаль тискәре зыяннарның авырлыгын һәм тиешле мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималын бәяләүне исәпкә алып, вәкаләтле орган боерыгы белән гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органның эш бирүче эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү турындагы боерыгы булмаганда, эш бирүченең эшчәнлеге түбән рисктагы категориягә кертелгән дип санала.

Уртача рисктагы категориягә юридик затлар яки индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеге түбәндәге очракларда кертелә:

чираттагы календарь елга план буенча тикшерүләр үткәрү планын төзү датасына карата инвалидларны эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр тарафыннан тиешенчә үтәлмәгән, өлешчә үтәлгән, билгеләнгән вакытларны бозып үтәлгән күрсәтмә булганда;

чираттагы календарь елга план буенча тикшерүләр үткәрү планын төзү датасына кадәрге ел эчендә юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр тарафыннан инвалидларны эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау һәм инвалидларны эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрү турында кисәтү биргән вәкаләтле органга мондый кисәтүне үтәү йә мондый кисәтүгә каршы килүләр турында хәбәрнамә бирү буенча үтәлмәгән йөкләмә булганда.

Урта рисктагы категориягә, әгәр дә чираттагы календарь елга план буенча тикшерүләр үткәрү планын төзү датасына кадәрге ел эчендә юридик зат яки

индивидуаль эшмәкәр түбәндәгеләр өчен административ җаваплылыкка тартылган булса, юридик затлар яки индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеге керә:

инвалидларны эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәне үтәмәү;

инвалидларны эшкә кабул итү өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булдыру яки бүлеп бирү буенча йөкләмәләрне үтәмәү;

билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә кабул итүдән баш тарту;

инвалидларны эшкә кабул итү өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булдыру яки бүлеп бирү турындагы белешмәләрне (мәгълүматны) бирмәү яки үз вакытында бирмәү.

Эш бирүчеләр эшчәнлеген урта һәм уртача рисктагы категорияләргә кертү мөмкинлеген бирә торган шартлар булмаганда, эш бирүчеләрнең эшчәнлеге түбән рисктагы категориягә кертелә.

$16^2$. Эш бирүче Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тикшерүенең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда рискка юнәлдерелгән алымны куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары белән расланган Юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар куллана торган җитештерү объектларын билгеле бер риск категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле органга әлеге күзәтчелек һәм тикшерүдә тоту буенча үз эшчәнлегенә элек бирелгән риск категориясе үзгәрү турында гариза бирергә хокуклы.

$16^3$. Күзәтчелек һәм тикшерүдә тоту кысаларында эш бирүчеләрне план буенча тикшерүләрне үткәрү, аларның эшчәнлегенә бирелгән риск категориясеннән чыгып, түбәндәге вакыт дәвамлылыгында гамәлгә ашырыла:

урта рисктагы категория өчен – 4 елга бер тапкырдан ешрак һәм 5 елга бер тапкырдан сирәк булмаган вакыт эчендә;

уртача рисктагы категория өчен – 6 елга бер тапкырдан ешрак һәм 8 елга бер тапкырдан сирәк булмаган вакыт эчендә.

Эшчәнлекләре түбән рисктагы категориягә кертелгән эш бирүчеләргә карата план буенча тикшерүләр үткәрелми.

$16^4$. Вәкаләтле орган эшчәнлекләренә риск категориясе бирелгән субъектлар исемлекләрен (алга таба – исемлекләр) алып бара. Эш бирүчеләрне исемлекләргә кертү вәкаләтле органның бу Тәртипнең $16^1$ нче пункты нигезендә кабул ителгән юридик затлар яки индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү турындагы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

$16^5$. Исемлекләрдә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

юридик затның тулы исеме яки эшчәнлегенә риск категориясе бирелгән индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең индивидуаль номеры;

юридик затның адресы яки индивидуаль эшмәкәрнең яшәү урыны адресы (кирәк булганда элемтәгә керү өчен башка почта адресы), телефон һәм электрон почта адресы (булганда);

эш бирүче эшчәнлегенә элек бирелгән риск категориясе турында мәгълүмат;

вәкаләтле органның юридик затлар яки индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү турындагы боерыгы реквизитлары;

вәкаләтле органның юридик затлар якт индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү турындагы боерыгын кабул итү өчен нигез булган мәгълүматлар.

$16^6$. Эш бирүченең соравы буенча вәкаләтле орган мондый сорау кергән көннән 15 эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә аңа аның эшчәнлегенә бирелгән риск категориясе турында мәгълүмат, шулай ук аның эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә керткәндә файдаланылган белешмәләр җибәрә.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин